КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 декабрь г.Казань № 1710

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм инвентаре сатып алу буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 март, 193 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм инвентаре сатып алу буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 март, 193 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 декабрь , 1357 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «спорт әзерлеге оешмаларының норматив халәтенә» сүзләрен «спорт мәктәбе» дигән махсус исемле, үз исемендә «олимпия» сүзен яки аның нигезендә ясалган сүзләрне яки сүзтезмәләрне кулланучы өстәмә белем бирү оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «спорт әзерлеге оешмаларының норматив халәтенә» сүзләрен «спорт мәктәбе» дигән махсус исемле, үз исемендә «олимпия» сүзен яки аның нигезендә ясалган сүзләрне яки сүзтезмәләрне куллanучы өстәмә белем бирү оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм инвентаре сатып алу буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «спорт әзерлеге оешмаларының норматив халәтенә» сүзләрен «спорт мәктәбе» дигән махсус исемле, үз исемендә «олимпия» сүзен яки аның нигезендә ясалган сүзләрне яки сүзтезмәләрне кулланучы өстәмә белем бирү оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2026 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 159 нчы карары белән расланган «2019 – 2026 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында «спорт мәктәбе» дигән махсус исемле, үз исемендә «олимпия» сүзен яки аның нигезендә ясалган сүзләрне яки сүзтезмәләрне кулланучы өстәмә белем бирү оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең (алга таба – муниципаль берәмлекләр) спорт җиһазлары һәм инвентарь сатып алу буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.»;

4 пунктның икенче абзацында «спорт әзерлеге оешмаларының норматив халәтенә» сүзләрен «спорт мәктәбе» дигән махсус исемле, үз исемендә «олимпия» сүзен яки аның нигезендә ясалган сүзләрне яки сүзтезмәләрне кулланучы өстәмә белем бирү оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары муниципаль берәмлек территориясендә җирле бюджет акчалары исәбеннән спорт әзерлегенең федераль стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы олимпия резервындагы спорт мәктәпләре булу (алга таба - олимпия резервындагы спорт мәктәбе).»;

6 пунктта:

икенче абзацта «чаралар» сүзен «чаралар (нәтиҗәләр)» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«олимпия резервындагы барлык спорт мәктәпләре халыкка спорт әзерлегенең федераль стандартлары һәм спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары нигезендә хезмәт күрсәтәләр;»;

өченче абзацта «олимпия резервындагы спорт мәктәпләре өлешендә спорт әзерлеге оешмаларының» сүзләрен «олимпия резервындагы спорт мәктәпләренең» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин